ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25 октябрь 2024ел № 7077

Башкарма комитетның 2022 елның 19 сентябрендәге 4881 номерлы Карары белән расланган күпфатирлы йорттагы бүлмәне үзгәртеп коруны һәм (яки) яңадан планлаштыруны үткәрүне килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Күпфатирлы йорттагы бүлмәне үзгәртеп кору һәм (яки) яңадан планлаштыру турында гариза формасын һәм күпфатирлы йорттагы бүлмәне үзгәртеп коруны һәм (яки) яңадан планлаштыруны килештерү яки килештерүдән баш тарту турында карар кабул итүне раслаучы документ формасын раслау хакында» 2024 елның 4 апрелендәге 240/пр номерлы приказы, шәһәр Уставының 42 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2022 елның 19 сентябрендәге 4881 номерлы Карары белән (Башкарма комитетның 2023 елның 16 июнендәге 5184 номерлы, 2024 елның 16 февралендәге 1004 номерлы, 2024 елның 13 июнендәге 3755 номерлы Карарлары редакциясендә) расланган күпфатирлы йорттагы бүлмәне үзгәртеп коруны һәм (яки) яңадан планлаштыруны үткәрүне килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче кушымтаны 1 нче кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә;

2) 3 нче кушымтаны 2 нче кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев

Башкарма комитетның
2024 елның 25 октябрендәге
7077 номерлы карарына
1 нче кушымта

Күпфатирлы йорттагы бүлмәне үзгәртеп коруны һәм (яки) яңадан планлаштыруны үткәрүне килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
1 нче кушымта

ФОРМА

Күпфатирлы йорттагы бүлмәне үзгәртеп коруны һәм (яки) яңадан планлаштыруны килештерү турында яки килештерүдән баш тарту турында
КАРАР

______________________________________________________________________________

(юридик затлар өчен – тулы һәм кыскартылган (булган очракта) исеме, төп дәүләт теркәү номеры (чит ил юридик заты өчен – теркәлгән (инкорпорацияләнгән) илдә әлеге юридик затка бирелгән теркәү номеры яки аның аналогы); физик затлар өчен – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), шәхесен таныклаучы документның сериясе һәм номеры, яшәү урыны буенча теркәлү адресы; дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнары өчен – органның тулы һәм кыскартылган (булган очракта) исеме, аның нигезендә әлеге органның эшчәнлеге гамәлгә ашырыла торган норматив хокукый актның реквизитлары)

______________________________________________________________________________

(Россия Федерациясе субъекты, муниципаль берәмлек, урам, йорт, корпус, төзелеш, фатир (бүлмә), бүлмә номеры (соңгысы – торак булмаган бүлмәләр өчен), күчемсез мөлкәт объектының кадастр номеры)
адресы буенча күпфатирлы йорттагы бүлмәне үзгәртеп кору һәм (яки) яңадан планлаштыру турында

______________________________________________________________________________

(күпфатирлы йорттагы бүлмәне үзгәртеп кору һәм (яки) яңадан планлаштыру турында гаризаның номеры һәм датасы)

гариза бирү сәбәпле,

______________________________________________________________________________.

(күпфатирлы йорттагы үзгәртеп корыла һәм (яки) яңадан планлаштырыла торган бүлмәне үзгәртеп кору һәм (яки) яңадан планлаштыру проектының исеме, номеры һәм датасы)
проект нигезендә

гаризаны һәм Россия Федерациясе Торак кодексының 26 статьясындагы 2 һәм 2.1 өлешләре нигезендә тапшырылган башка документларны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча карар кабул ителде:

______________________________________________________________________________

(күпфатирлы йорттагы бүлмәне үзгәртеп коруны һәм (яки) яңадан планлаштыруны килештерү турында яки, баш тарту нигезен күрсәтеп һәм Россия Федерациясе Торак кодексының 27 статьясындагы 1 өлешендә каралган хокук бозуларга сылтама белән, килештерүдән баш тарту турында карар).

| | | |
|---|---|---|
| «__» _______ 20__ ел | ______________________________ | ______________________________ |
| (карар кабул итү датасы) | (килештерүне гамәлгә ашыручы вазыйфаи зат имзасы) | (вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) |

Карар шәхсән кабул итеп алынды:

«__» _______ 20__ ел

| | | |
|---|---|---|
| «__» _______ 20__ ел | _______________________ (гариза бирүченең яки аның тарафыннан вәкаләтләнгән затның имзасы) | _______________________ (фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) |

Карар гариза бирүченең адресына җибәрелде (карар почта аша җибәрелгән очракта тутырыла) «__» _______ 20__ ел

| | | |
|---|---|---|
| _______________ (вазыйфасы) | _______________________ (килештерүне гамәлгә ашыручы вазыйфаи зат имзасы) | _______________________ (фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) |

Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе урынбасары, эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы вазыйфаларын башкаручы Г.А. Шәфыйкова

Башкарма комитетның
2024 елның 25 октябрендәге
7077 номерлы карарына
2 нче кушымта

Күпфатирлы йорттагы бүлмәне үзгәртеп коруны һәм (яки) яңадан планлаштыруны үткәрүне килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
3 нче кушымта

ФОРМА

______________________________________
______________________________________
(күпфатирлы йорттагы үзгәртеп корыла һәм (яки) яңадан планлаштырыла торган бүлмә урнашкан урын буенча җирле үзидарә органының исеме)

Күпфатирлы йорттагы бүлмәне
үзгәртеп кору һәм (яки) яңадан планлаштыру турында
ГАРИЗА

______________________________________________________________________
(юридик затлар өчен – тулы һәм кыскартылган (булган очракта) исеме, төп дәүләт теркәү номеры (чит ил юридик заты өчен - теркәлгән (инкорпорацияләнгән) илдә әлеге юридик затка бирелгән теркәү номеры яки аның аналогы); физик затлар өчен – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), шәхесен таныклаучы документның сериясе һәм номеры, яшәү урыны буенча теркәлү адресы; дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнары өчен – органның тулы һәм кыскартылган (булган очракта) исеме, аның нигезендә әлеге органның эшчәнлеге гамәлгә ашырыла торган норматив хокукый актның реквизитлары)

Күпфатирлы йорттагы бүлмәне ____________________________________________
(үзгәртеп кору, яңадан планлаштыру яки үзгәртеп кору һәм яңадан планлаштыру)

буенча тәкъдим ителгән проект нигезендә,

______________________________________________________________________
(Россия Федерациясе субъекты, муниципаль берәмлек, урам, йорт, корпус, төзелеш, фатир (бүлмә), бүлмә номеры (соңгысы – торак булмаган бүлмәләр өчен), күчемсез мөлкәт объектының кадастр номеры)

адресы буенча күпфатирлы йорттагы бүлмәне ________________________________
(үзгәртеп кору, яңадан планлаштыру яки үзгәртеп кору һәм яңадан планлаштыру)

килештерүне сорыйм.

Күпфатирлы йорттагы бүлмәне үзгәртеп кору һәм (яки) яңадан планлаштыру турында гаризага түбәндәге документлар теркәлә:

1) ______________________________________________________________

______________________________________________________________

____________________________________________________ _____ биттә;

(күпфатирлы йорттагы үзгәртеп корыла һәм (яки) яңадан планлаштырыла торган бүлмәгә хокук билгеләүче документларның төре, номеры һәм датасы (әгәр күпфатирлы йорттагы үзгәртеп корыла һәм (яки) яңадан планлаштырыла торган бүлмәгә хокук Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында теркәлгән булса, документ гариза бирүче инициативасы буенча тапшырыла)

2) проект ______________________________________________________

____________________________________________________ _____ биттә;

(күпфатирлы йорттагы үзгәртеп корыла һәм (яки) яңадан планлаштырыла торган бүлмәне үзгәртеп кору һәм (яки) яңадан планлаштыру проектының исеме, номеры һәм датасы)

3) күпфатирлы йорттагы торак милекчеләренең гомуми җыелышы беркетмәсе

______________________________________________________________

____________________________________________________ _____ биттә;

(Россия Федерациясе Торак кодексының 40 статьясындагы 2 өлешендә каралган очракта, күпфатирлы йорттагы барлык торак милекчеләренең күпфатирлы йорттагы бүмәне үзгәртеп коруга һәм (яки) яңадан планлаштыруга ризалыгы турында күпфатирлы йорттагы торак милекчеләренең гомуми җыелышы беркетмәсенең исеме (булган очракта), номеры һәм датасы)

4) техник паспорт ______________________________________________

____________________________________________________ _____ биттә;

(күпфатирлы йорттагы үзгәртеп корыла һәм (яки) яңадан планлаштырыла торган бүлмәнең техник паспортының номеры һәм бирү датасы) (документ гариза бирүченең инициативасы буенча тапшырыла)

5) гариза бирүче гаиләсенең социаль наем шартнамәсе буенча торак урынны биләгән барлык әгъзаларының ризалыгы _____ биттә;

______________________________________________________________

(әгәр гариза бирүче булып, наемга бирүче тарафыннан әлеге пунктта каралган документларны тапшыруга вәкаләтләнгән, үзгәртеп корыла һәм (яки) яңадан планлаштырыла торган торакны социаль наем шартнамәсе буенча наемга алучы (шул исәптән наемга алучы гаиләсенең вакытлыча булмаган әгъзалары) торса)

6) бәяләмә ______________________________________________________

____________________________________________________ _____ биттә;

(номеры, бирү датасы һәм күпфатирлы йорттагы бүлмәне үзгәртеп коруны һәм (яки) яңадан планлаштыруны үткәрү рөхсәт ителү турында бәяләмә биргән архитектура, тарих һәм мәдәният ядкарьләрен саклау органының исеме, әгәр ул урнашкан бина яки йорт архитектура, тарих яки мәдәният ядкәре булып торса) (документ гариза бирүченең инициативасы буенча тапшырыла)

7) ______________________________________________________________

____________________________________________________ _____ биттә.

(гариза бирүченең вәкаләтләрен раслый торган документ төре, номеры һәм датасы)

«____» __________ 20 ел

| | | |
|---|---|---|
| | ________________________ | ________________________ |
| | гариза бирүченең яки аның тарафыннан вәкаләтләнгән затның имзасы) | (фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) |

Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе урынбасары, эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы вазыйфаларын башкаручы Г.А. Шәфыйкова